

«Авыл хуҗалыгы тармагында зур эшче һәм профессионал, талантлы җитәкче һәм җитештерүне оста оештыручы. Өч дистә елдан артык Габделхай Йосыф улы туган Арча җирендә актив хезмәт куйды. Агросәнәгать комплексын модернизацияләүгә һәм үстерүгә зур өлеш кертте, социаль проектларда, районны төзекләндерүдә актив катнашты»

*Татарстан Республикасы Рәисе*
*Рөстәм Нургалиевич Минниханов*

**Кәримов Габделхай Юсупович**
1961 нче елның 1 августында Арча районы Шушмабаш авылында туа.
1968-1978 – Шушмабаш урта мәктәбендә белем ала.
Беренче укытучысы- Гөлбостан Рауповна.
1978-1981 елларда Савал авыл хуҗалыгы техникумында укый.
1988 елда М. Горький исемендәге Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтында югары белем ала.
2000 елда Татар бизнеска ярдәм институтын тәмамлый.
2007 елдан «Сервис-Агро» ҖЧҖ директоры.
2019 елның сентябреннән — алтынчы чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты.



**Мактаулы исемнәре**

- РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре;
- ТР атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре;
- «Россия агросәнәгать комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» алтын медаль;
- "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" медале;
- «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә.

**Игенчелектә дә, терлекчелектә дә революция ясаган шәхес**

“Дәүләт Советы депутаты Габделхай Йосыф улы Кәримов - күренекле эшмәкәр, чын аграрчы, татар халкының патриоты, республиканың авыл территорияләрен торгызу өчен барысын да эшләгән кеше”

*ТР Дәүләт Советы депутаты Таһир Һадиев*

Габделхай Юсуповичның эшкә тугрылыгы, профессионализмы, кешеләргә игътибарлы мөнәсәбәте аны республикада абруйлы шәхес итеп таныта.

Хезмәт эшчәнлеген 1981 елда Арча районының «Яңа Кенәр» совхозында агроном-семеновод вазифасында башлый. 1983 елдан Арча районы колхозларында һәм «Сортсемовощ» республика берләшмәсендә баш агроном булып эшли. 1991 елдан алып Биектау районының «Семеновод» МП һәм «Калининский» совхозы директоры булып тора. 1995 елда Биектау районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы итеп билгеләнә. 1997 елда «Сервис-Агро» ҖЧҖ не җитәкли.
Энергияле, җаваплы һәм инициативалы хезмәткәр үзен белемле белгеч, яхшы оештыручы итеп күрсәтә. Аның хезмәте нәтиҗәсендә югары продуктлы районлаштырылган сортлар әйләнешкә кертелә. Туфракны эшкәртү, югары технологияләр куллану, ашламалар кертү югары уңыш алырга мөмкинлек бирә.

Габделхай Йосыф улы Кәримов республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә һәм модернизацияләүгә зур өлеш кертә, Арча муниципаль районының социаль-икътисади үсешендә һәм аны төзекләндерүдә актив катнаша. Аның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм казанышлары югары бүләкләр белән билгеләп үтелә, алар арасында «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» һәм «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» мактаулы исемнәре, «Фидакарь хезмәт өчен» һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте. Ул «Ел җитәкчесе – 2016» Республика иҗтимагый конкурсы лауреаты булды. Габделхай Кәримов максатчан һәм талантлы оештыручы, сизгер һәм игътибарлы остаз була.

Габделхай Кәримов дөньяның күп кенә илләрендә була, аларның тәҗрибәсен өйрәнә, кайбер яңалыкларны файдалы дип саный, үз эшчәнлегендә дә куллана. “Игенчелектә дә, терлекчелектә дә революция ясаган”, — дип сөйлиләр аның турында. Барлык белемнәрен һәм көчен авыл хуҗалыгы җирләрен нәтиҗәле куллануга, интенсив һәм ресурсларны саклаучы технологияләрне кертүгә юнәлтә. Авылның социаль һәм инженерлык үсешенә, гади авыл хезмәтчәннәренең тормышын яхшыртуга зур игътибар бирә.

2007 елдан «Сервис-Агро» ҖЧҖ директоры вазифасын үти. Ул республикада беренчеләрдән булып яшелчә культуралары орлыклары үстерү буенча кооператив ачты, «Сервис-Агро» предприятиесенә кергән «Кырлай» агрофирмасы белән җитәкчелек итте. Хәзер аны Габделхай Йосыповичның улы Марат Кәримов җитәкли. Ул балачактан ук әтисенең нинди фидакарьлек белән эшләвен күргән, һәрвакыт якынына ярдәм итәргә омтыла. Марат әтисенең башлангычын лаеклы дәвам итә, һәрнәрсәдә лидер булырга тырыша. Нәкъ менә «Кырлай» агрофирмасы районда яңа

технологияләр куллана башлаган - биредә авыл хуҗалыгы хайваннарын чиплаганнар, сөрү җирләрен цифрлаштырганнар.

Габделхәй Кәримов күп эшләр башкарырга өлгерә: Яңа Кырлай авылында күңел ачу-кунак шәһәр читендәге комплекс төзи, ул Арча районының чын үзенчәлеге булып тора.

**Авылының игелекле улы**

Милли бәйрәмебез Сабан туйларының берсендә мәйдан уртасына Габделхай Йосыф улы Кәримовны чакыралар, “Авылның игелекле улы” исеменә лаек булуын белдерәләр. Бу олы хөрмәт – аның туган ягына, халыкка күрсәткән хезмәтләренә иң югары бәядер.

Тормыш юлын да җир белән бәйли ул һәм гомер буе сайлаган һөнәренә тугры кала. Арча ягына инвестор булып килә ул.

Габделхай Йосыф улы өчен төп нигез – үз йорты гына түгел, ул бөтен авыл. Һәр нәрсәнең төпле, урынлы, матур булуы, иманлы, йөз кызармаслык итеп көн күрү – аның тормыш токтасы.

Габделхай Йосыф улы нәкъ менә шундый олпат, олуг, олы йөрәкле шәхес иде. 59 нчы яшендә, бик иртә арабыздан мәңгелеккә китеп барса да, игелекле эшләре белән ул авылыбыз халкы күңеленә кереп урнашты. Үзе туып үскән авылны ныгытырга, яңартырга теләгән һәм ирешкән шәхес туган авылында тирә якны балкытып утырган мәчет төзетте, Шушмабаш табиблык амбулаториясенә капиталь ремонт, ашыгыч ярдәм машинасы алып бирү, авылыбыз зиратын койма белән әйләндереп алу, һәр уку елы башында 1 класс укучыларына рюкзак тапшыру - ул эшләгән игелекле эшләрнең бер өлеше генә.

Авылыбызның даһи улы Габделхай Йосыф улы исемен мәңгеләштерү йөзеннән Арча районы башлыгы карары нигезендә үзе укыган Шушмабаш урта мәктәбендә мемориаль такта ачылды. Шулай ук мәктәбебезнең аграр классына Габделхай Кәримов исеме бирелде. Яшь буын өчен Габделхай абыебыз горурлык, батырлык үрнәге булып тора.



